**КАРАР**
**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы**
**Яңасала авыл җирлеге Шәпкә авылында**
**гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

4 нче декабрь 2019 ел № 2

"Россия Федерациясендә җирле узидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 121-ФЗ номерлы Федераль законнын 25,1, 56 статьялары, "Татарстан Рес публикасында җирле узидарә турында" 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 нчы елның 3нче декабрендә булып узган гражданнар жыены нәтиҗәләре нигезендә түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде: «2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге территориясе, Шәпкә авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

**- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау: Шәпкә авылы;**

**- Шәпкә авылында җәяүлеләр күперен ремонтлау;**

**- Шәпкә авылындагы чишмәләрне ремонтлау;**

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 101 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 59 кеше тавыш бирүдә катнашкан.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде::

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы59 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте**:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Яңасала авыл җирлеге составына керүче Шәпкә авылы халык җыенын узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләрен дөрес дип санарга.

2. «2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге территориясе, Шәпкә авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерүгә җибәрүгә килешәсезме:

**- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау: Шәпкә авылы;**

**- Шәпкә авылында җәяүлеләр күперен ремонтлау;**

**- Шәпкә авылындагы чишмәләрне ремонтлау;**» соравы буенча карарны кабул ителгән дип таныргa..

3. 2020 елда Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Яңасала авыл җирлеге территориясе, Шәпкә авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлдерергә:

**- җирлек эчендәге юлларны ремонтлау: Шәпкә авылы;**
**- Шәпкә авылында җәяүлеләр күперен ремонтлау;**
**- Шәпкә авылындагы чишмәләрне ремонтлау.**»

4. Гражданнар җыены нәтиҗәләрен түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында игълан итәргә:

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Олы Яңасала авылы, Үзәк урам, 1;

-Татарстан Республикасы, Кама Тамагы районы, Шәпкә авылы, Клуб урамы, 14,шулай ук Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

Халык җыенында рәислек итүче ,
Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Яңасала авыл җирлеге
башлыгы: И.Х.Шиһабеев